Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР

15 июня 2022 года №20

Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрель 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексы нигезендә, Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Зур Кукмара авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрель 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Зур Кукмара авыл җирлеге Советның 2018 елның 07 ноябрендәге29 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 10 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 7 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 6 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1. пунктында:

а) 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын (подданнствосын) туктату турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы (подданнствосы) туктатылганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча язмача хәбәр итәргә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктчасын өстәргә:

«9.1. яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) чит ил гражданлыгы (подданство) алу турында яисә гражданның яшәү төре алуы яки чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алуы турында муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма чит ил гражданлыгы (подданство) алганнан яисә гражданның яшәү төре алган яки чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алган көненнән 5 көннән дә соңга калмыйча язмача хәбәр итәргә;

1.2. 8 бүлекнең 1 пунктында:

а) 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит ил гражданлыгын (подданство) туктату;»;

б) 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) гражданның чит ил гражданлыгы (подданство) йә яшәү төре яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

1.3. 15 бүлектәге 1 пунктның 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: Р.Р.Хәнәфиев